ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.08.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1576**

Зеленодольск шәһәре предприятиеләреннән үзәкләштерелгән су бүлеп бирү системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агынты сулардагы зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре нормаларыбуенча

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең 2018 елның 05 октябрендәге СВ 32.12.18.59 номерлы әйләнә-тирә мохиткә (су объектларына) зарарлы(пычраткыч) матдәләр агызуга рөхсәт язуы (лицензиясе) нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 1 июленнән «Агымдагы сулар составын һәм үзлекләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 728 номерлы карары үз көченә керүгә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы (22.05.2020 нче редакциясендә) карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре предприятиеләреннән «ЗВКС» акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән су бүлеп бирү системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агынты сулардагы зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре нормаларын расларга. (кушымта). Күрсәтелгән нормалар күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга (әлеге абонентлардан биологик чистарту корылмаларына керә торган агынтыларның (стокларның) рөхсәт ителгән иң чик концентрациясе нормалаштырылмый) кагылмый. Әлеге карарның гамәлдә булу вакытын 2021 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 июленнән таратырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 13 декабрендә кабул ителгән 2742 номерлы «Зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре нормалары буенча» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. ЗМР Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга, «Зеленый Дол» һәм «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Кушымта

## Су объектына (Идел елгасына) тискәре йогынтыны булдырмау максатыннан куелган, абонентларның агынты суларында зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе нормасы

| Зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең исеме | Предприятиеләрнең агынты суларын чыгаруда зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе, мг/л |
|---|---|
| Алюминий | 0,175 |
| Аммоний ион | 25 |
| БПК5 | 300 |
| Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| Тимер | 1,025 |
| Кальций | 200,4 |
| Магний | 39,00 |
| Марганец | 0,0738 |
| Бакыр | 0,0055 |
| Нефть продуктлары | 3,597 |
| Нитратлар | Норматив билгеләнми |
| Нитрит | Норматив билгеләнми |
| СПАВ (АПАВ) | 10 |
| Сульфатлар | 125,41 |
| Корыган калдык | 1043,62 |
| Фенол | 0,007 |
| Формальдегид | 0,044 |
| Фосфатлар (фосфор буенча) | 12 |
| Хлоридлар | 342,50 |
| Цинк | 0,1285 |

Искәрмә:

1. Нефть продуктлары эретелгән эмульгацияләнгән халәттә генә агызыла.
2. Югарыда күрсәтелмәгән пычраткыч матдәләр ташлау тыела.